«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ
**ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ИНСТИТУТЫ**»
ДӘҮЛӘТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

ГОСУДАРСТВЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«**ИНСТИТУТ ТАТАРСКОЙ ЭНЦИКЛОПЕДИИ**
АКАДЕМИИ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

№ 6 от "23" 09 2011 г.
на № ____ от "____" ________ 2011 г.

420015 г.Казань, ул.Пушкина, 56
тел. (843) 238-35-82, 238-25-68
тел./факс (843) 238-25-58
E-mail: info-ite@mail.ru

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
Мәдәният, фән, мәгариф
һәм милли мәсьәләләр
комитеты рәисе
Разил Исмәгыйль улы Вәлиевкә

Хөрмәтле Разил әфәнде!

Сезнең Татар Википедиясен җәелдерүгә булышлык итү турындагы мөрәҗәгатегезгә (8.09.2011) җавап йөзеннән игътибарыгызны түбәндәгеләргә юнәлдерер идек:

Татар Википедиясе барлыкка килү, һичшиксез, иҗтимагый-сәяси әһәмияткә ия вакыйга, чөнки ул татар теленең интернет челтәреннән читтә дә таралашына, кулланылышына, гомумән алганда, яшәешенә һәм үсешенә хезмәт итә.

Шул ук вакытта, искәртик, Википедия баштан ук иреклe, һәртөрле цензурадан азат интернет-энциклопедия булып дөньяга килә, теләге булган һәр кеше аның авторы була ала. Мәкаләләрне бу рәвешле урнаштыруның уңай яклар белән бергә тискәре яклары да бар: беренче чиратта бу төр энциклопедиянең субъективлык белән сыйфатлануын әйтергә кирәк. Мәкаләләрне сайлап алуның катгый критерийлары юк, аларның фәннилеге шикле, нәкъ шушы сәбәпләр проектны ышанычсыз итә. Бу әле – йомшак итеп әйткәндә; Ә мәсьәләгә таләпчән күз белән карасак, Википедияне “электрон чүп кәрҗине”нә тиңләргә дә була.

Күптомлы Татар энциклопедиясе нигезендә тарихи дөреслек, фәннилек, объективлык ята, терминнар һәм персоналийлар (шәхесләр исемлеге) аерым критерийлардан чыгып, республиканың абруйлы галимнәре тарафыннан сайлап алына, энциклопедиянең эчтәлеге һәм формасы академизм калыбына салынган дип әйтергә кирәк. Энциклопедия авторларын, югарыда әйтелгәнчә, галимнәрнең иң абруйлылары: академиклар, фән докторлары, төрле өлкәләрдә Татарстан һәм Россия күләмендә танылган белгечләр тәшкил итә. Шуңа күрә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
«24» 09 20 11 г.
Керү
Вх. № 7276
ИНН 1654014349 Р.74555/17

күптомлы Татар энциклопедиясе һәм Татар Википедиясе төзүнең максатлары һәм алгоритмы, әлбәттә, бер-берсеннән бик нык аерыла.

Бүгенге көнгә Татар энциклопедиясе лөгатьлеге 20 меңләп термин, төшенчә һәм шәхес исемен эченә ала. Бу шул ук санда мәкалә әзерләнгән дигән сүз. Аларның 6 меңләбе энциклопедиянең татарча вариантында (I һәм II том) татар телендә дөнья күрде. Бу мәкаләләрне Татар Википедиясенә турыдан-туры күчерү (11341 мәкалә әзер), әлбәттә, безне сан ягыннан Чуаш Википедиясенә (12911 мәкалә) якынайтыр, әмма Казакъ (75710 мәкалә), Әзәрбайҗан (81682 мәкалә), Төрек Википедиясен (172538 мәкалә) барыбер куып җитә алмабыз. Шунысын да онытмыйк: Татар энциклопедиясе материаллары авторлык хокуклары турындагы канун нигезендә яклана.

Татар энциклопедиясе институты Татар Википедиясен оештыручылар белән хезмәттәшлеккә әзер, шул исәптән энциклопедия томнарында урын алган материалларны уртаклашу юлы белән дә (Авторлык хокуклары турындагы законга хилафлык килмәгән очракта).

Сүз азагында Татар энциклопедиясе институтының алдагы ниятләре белән таныштыру урынлы булыр: иң якын планыбыз – энциклопедиябезнең һәм русча һәм татарча электрон версиясен булдырып, язма версиягә тәңгәл рәвештә яңартып тору. Әлбәттә, энциклопедия хәзинәләреннән теләге булган һәр кеше бушлай файдалана алачак. Менә бу юл Татар интернеты үсешендә әһәмиятле адым булыр.

ТР Фәннәр академиясенең
Татар энциклопедиясе институты
директоры

Р.М.Вәлиев